КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 17 декабрь г.Казань № 1158

Татарстан Республикасы Президентының 2020 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасын тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте гамәлләренең комплекслы планы турында

Татарстан Республикасы Президентының 2020 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасында билгеләнгән төп нигезләмәләрне һәм бурычларны тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы Президентының 2020 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасын тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте гамәлләренең комплекслы планын (алга таба – План) расларга.

2. Планны тормышка ашыруда катнашучы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына хисап кварталыннан соң килүче айның 10ысына кадәр аны үтәү барышы турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына кертергә.

3. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Планны тормышка ашыруда катнашучы федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, Татарстан Республикасы предприятиеләренә һәм оешмаларына хисап кварталыннан соң килүче айның 10ысына кадәр аны үтәү барышы турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына кертүне;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы Президентының 2020 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасында билгеләнгән төп нигезләмәләрне һәм

бурычларны тормышка ашыру буенча чаралар күрүне һәм хисап кварталыннан соң килүче айның 10ысына кадәр аны үтәү барышы турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына кертүне.

4. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына хисап кварталыннан соң килүче икенче айның 10ысына кадәр алынган мәгълүматны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин